ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.10.2019 Олы Кайбыч ав. № 457

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 04 июлендәге 309 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән һәм өченче зат хокукларыннан азат булган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлегенә өстәмәләр кертү турында

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 15 статьясы, 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 04 июлендәге 309 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән һәм өченче зат хокукларыннан азат булган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген 4 һәм 5 пунктлар белән түбәндәге эчтәлекле өстәмәләр кертергә:

| п/п | Милек исеме | Бинаның гомуми мәйданы | Урнашу урыны (адресы) |
|---|---|---|---|
| 4 | 16:21:120401:105 кадастр номерлы башлангыч мәктәп бинасы (гамәлдә түгел) | 53,5 | Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Мәлки авыл җирлеге, Яңа Буа авылы, Үзәк ур., 49 й. |
| 5 | 16:21:140301:286 кадастр номерлы Турминский башлангыч мәктәбе – балалар бакчасы бинасы (гамәлдә түгел) | 253,8 | Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Хуҗа Хәсән авыл җирлеге, Турминский авылы, Үзәк ур., 47 й. |

2. Әлеге карарны мәгълүматый – телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы» МКУ Рәисе О.Д.Макаровага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров